**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**2020 елның 7 сентябре** **№ 273**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнарының сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы контроль-хисап палатасы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында» 2018 елның 16 апрелендәге 133 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында (2018 елның 14 маендагы 137 номерлы, 2018 елның 27 августындагы 143 номерлы, 2018 елның 11 декабрендәге 163 номерлы, 2019 елның 30 декабрендәге 242 номерлы карарлар редакциясендә)**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы Карарын үтәү йөзеннән, муниципаль берәмлекләр башлыкларының айлык акчалата түләүләре күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарлары, депутатлар, Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары, алар биләгән муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә "Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында " 2018 елның 28 июнендәге 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән тәртиптә

билгеләнә., үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 24 апрелендәге 281 номерлы, 14.06.2018 ел, № 481, 17.10.2018 ел, № 940, 29.12.2018 ел, № 1320 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2018 елның 16 апрелендәге 133 номерлы карарына "Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнарының сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап палатасы Рәисенең, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү турында»(Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2018 елның 14 маендагы 137 номерлы, 2018 елның 27 августындагы 143 номерлы, 2018 елның 12 декабрендәге 163 номерлы, 2019 елның 30 декабрендәге 242 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктта «11 163,00» саннарын «11 498,00» саннарына алмаштырырга.

Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының күләмнәрен исәпләп чыгару өчен авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләмен 1,03 мәртәбә индексацияләү һәм аны 11498 сум күләмендә билгеләү.

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Муниципаль районның җирле үзидарә органнарына гамәлдәге законнар таләпләренә норматив хокукый актларны туры китерергә һәм шундый ук карар кабул итәргә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанс буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Кама Тамагы муниципаль**
**районы башлыгы-**
**Кама Тамагы муниципаль**
**районы Советы рәисе** **Н.А. Вазыйхов**